ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26 декабрь 2017 ел. № 8124

Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр мунчалары» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган мунча хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында

Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр мунчалары» МКП мөрәҗәгатен караганнан соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль Законның 17 маддәсендәге 1 пунктның 4 пунктчасына, Яр Чаллы шәһәре Уставының 28 маддәсендәге 1 пунктның 7 пунктчасына, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәгә, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе хакындагы нигезнамәгә туры китереп

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр мунчалары» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган мунча хезмәтләренә тарифларны кушымтада каралганча расларга һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.
2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр мунчалары» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган мунча хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында» 2016 елның 26 гыйнварындагы 264 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастыруны, Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 26 декабрендәге
8124 нче карарына
кушымта

Мунча хезмәтләренә тарифлар

| Т/с | Халык категориясе | 1 кешегә хезмәттән файдалану дәвамлылыгы | Тариф күләме, сум (өстәмә кыйммәткә салымнан тыш) |
|---|---|---|---|
| 1. | Мунчаларның гомуми бүлегендә юыну | | |
| - | Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар, фашист концлагерьларының балигъ булмаган тоткыннары, «Блокадаланган Ленинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар, Социалистик хезмәт Геройлары, СССР Геройлары | 1 сәгать 45 минут | түләүсез |
| - | Бөек Ватан сугышы инвалидлары | | |
| - | Диализда торучы, сәламәтлекләре буенча инвалидлар | | |
| - | 7 яшькә кадәрге балалар | | |
| - | «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ санлы Федераль законның 20 маддәсендә күздә тотылган Бөек Ватан сугышы ветераннары | | 85,00 |
| - | Һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннары | | |
| - | Барлык категория пенсионерлар | | 125,00 |
| - | Гражданнарның башка категорияләре | | 190,00 |
| 2. | Гражданнарның барлык категорияләре өчен бассейннан файдалану | 45 минут | 110,00 |
| 3. | Барлык категория пенсионерлар | | 90,00 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова